СОВЕТ АБСАЛЯМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
(IV созыв)

**РЕШЕНИЕ**
**внеочередного заседания IVсозыва**

**№ 17 с. Абсалямово 19 август 2025 ел**

Татарстан Республикасы Әбсәләм авыл җирлеге Советының 2024 елның 09 декабрендәге 26 санлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авыл җирлегендә бюджет процессы турында"гы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 33-ФЗ санлы Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советының 2024 елның 09 декабрендәге 26 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авыл җирлегендә бюджет процессы турында»гы нигезләмәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. 29 маддәнең 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль берәмлек башкарма комитеты касса планын төзү һәм алып бару тәртибен, шулай ук бюджет акчаларын баш урнаштыручылар, җирле бюджет керемнәренең Баш администраторлары, җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының Баш администраторлары тарафыннан касса планын төзү һәм алып бару өчен кирәкле белешмәләрне формалаштыру һәм тапшыру тәртибен, составын һәм вакытларын билгели.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми бастырып чыгару юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә (https://pravo.tatarstan.ru Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан 2013 елның 17 декабрендә бирелгән ЭЛ ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык) һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте

һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм порталын урнаштырырга. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адресы буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Әбсәләм авыл җирлеге башлыгы Г.В.Кубашева